| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 25.08.2017 | Казан ш. | № 10-19/кс |

Эчә торган суга, техник суга (әйләнешле су белән тәэмин ителешкә), су бүлүгә (сәнәгать һәм явым-төшем агынты суларына) тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчә торган суга, техник суга (әйләнешле су белән тәэмин ителешкә), су бүлүгә (сәнәгать һәм явым-төшем агынты суларына) тарифлар билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Шушы карар кушымтасында күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмаларга ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 25.08.2017
№ 10-19/кс карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен эчә торган суга,
техник суга (әйләнешле су белән тәэмин ителешкә) су бүлүгә (сәнәгать һәм явым-төшем агынты суларына)
тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су бүлүне гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Техник суга (әйләнешле су белән тәэмин ителешкә) тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Су бүлүгә (сәнәгать һәм явым-төшем агынты суларына) тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр | карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2017 кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | |
| 1 | «Сөләй ТКХ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 16,77 | | |
| | Казан шәһәре | | | |
| 2 | «Казаньоргсинтез» халыкка ачык акционерлык җәмгыяте (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | | 0,88 | 11,35 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге